РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**исполнительный комитет**
**Большесалтыковского сельского поселения**

422831, Республика Татарстан,
Камско-Устьинский район,
с. Б.Салтыки, ул.Х.Такташ, 132
тел. (8437) 35-8-19
ИНН 1622004644

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

422831, Татарстан Республикасы,
Кама Тамагы районы,
Олы Салтык авылы, .Х.Такташ урамы,
132
тел. (8437) 35-8-19
ИНН 1622004644

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**18.09.2019** **№43**

**Җирле референдум үткәрү**
**инициативасы турында**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында”гы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында”гы Татарстан Республикасы Законының 17 маддәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Уставының 15 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:
"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге территориясендә турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, (кондезге бүлектә укучы студентлардан кала) җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 300 (өч йоз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:
- Олы Салтык авылында юлларны ремонтлау,
- Олы Мәрәтхуҗа авылында зират коймасын ремонтлау,
- Каты көнкүреш калдыклары полигоннарын норматив хәлгә китерү,
- Олы Салтык авылында кое ремонтлау,
- Даныш авылында кулне чистарту.

**«ӘЙЕ»** **«ЮК»**

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт,

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71 йорт,

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 61 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авылы җирлеге
Башлыгы, Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авылы җирлеге
Советы рәисе Х.Х.Ибәтов